РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 20 » 04 2021 ел № 320

2019 елның 31 гыйнварындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 113 санлы карары белән расланган «Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр трассалары схемасын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»на үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Торак кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 210-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2010 елның 2 ноябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»гы 880 санлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты карары, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 санлы карары белән кабул ителгән "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2006 елның 12 гыйнварындагы 1 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. 2019 елның 31 гыйнварындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 113 санлы карары белән расланган «Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр трассалары схемасын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»на түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 2.8. бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 5 абзац өстәргә:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»;

1.2. 2 бүлекнең 2.9. бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлектәге 8 абзац өстәргә:

«6) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу турында Россия Федераль салым хезмәтеннән мәгълүмат керү.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталындагы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе С.П.Самонина